б) *Суда балык адашмас.*

в) *Сүз – чәчәк, мәкаль – букет.*

10. Җыйнак җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Салкын кыш җитте.*

**ә) *Кыш җитте.***

б) *Кояш сирәк чыга.*

в) *Бүген кар яуды.*

## II. Башыгызны эшләтегез.

**Җавап:** *игелек* **(2 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Сәгать сүзендә 6* ***хәреф****, 5* ***аваз*** *бар; бу сүздә 2* ***сузык*** *аваз, 3* ***тартык*** *аваз. Сүзләрнең дөрес язылышы* ***орфографик*** *сүзлекләрдә күрсәтелә. Каты, йомшак –* ***антоним*** *сүзләр. Бер тамырдан ясалган сүзләр* ***тамырдаш*** *сүзләр дип атала. -ны/-не –* ***төшем*** *килеше кушымчасы.* ***Сан*** *н и ч ә? н и ч ә н ч е? ничәү? сорауларына җавап бирә.* ***Фигыль*** *н и ш л и? н и ш л ә д е? н и ш л ә р? сорауларына җавап бирә.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Мисал өчен үрнәк бирелә, тик укучы башка сүзләр, синонимнар да файдаланган булырга мөмкин. Иң мөһиме: җөмлә төзелешенә, стиль, фактик һ.б. хаталарга игътибар итәргә кирәк.

*Урамнан малай белән кыз бара иде. Ә аларның алдыннан – әби. Юлда бик тайгыч. Әбинең аягы таеп китте дә егылды.*

*Малай үзенең портфелен кызга тоттырды да әбигә ярдәм итәргә ашыкты.*

в) *ук*.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Мәсәлән, абага, атама, ашлама, асрама, аждаһа, алабута. **(3 балл)**

## III.Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Татар телендә калын һәм **нечкә** сузыклар бар. **Ирен** гармониясе язуда чагылыш тапмый. Язуда авазлар **хәрефләр** белән белдерелә. **Туры** мәгънә – сүзнең төп мәгънәсе. Бәйләгеч кушымчалар сүз **ахырында** килә. Дәрәҗә белән төрләнә торган сыйфатлар **асыл** сыйфатлар була. **Урын** рәвеше эш яки хәлнең үтәлү урынын һәм юнәлешен белдерә. Юклык алмашлыклары сорау алмашлыклары алдына һич һәм **бер** сүзләрен кую юлы белән ясала. Фигыльләр **затланышлы** һәм затланышсыз була. Фигыльнең **юклык** төре – ма/-мә, -мый/-ми кушымчалары ялганып ясала.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(10 балл)**

Мисал өчен үрнәк бирелә, тик укучы башка сүзләр, синонимнар да файдаланган булырга мөмкин. Иң мөһиме: җөмлә төзелешенә, стиль, фактик һ.б. хаталарга игътибар итәргә кирәк.

*Ике алма*

*Кечкенә генә бер кыз урамнан ике алма алып кергән. Мөгаен, кемдер бүләк иткәндер.*

- *Әнием, кара, нинди матур алмалар!*
- *Әйе, матур! Мине дә сыйлыйсыңмы? – дип сораган әнисе.*
- *Кечкенә бала алмаларга карап алган. Ә аннары бер алманы тешләгән. Бер секундка уйланып торган да ... – икенчесен капкан.*

*Әнисе гаҗәпләнгән. ...*

*каршы мәгънәле сүзләр* ***антонимнар*** *дип атала. Яңа сүзләрне* ***неологизмнар*** *дип атыйлар.* ***Бәйләгеч*** *кушымчалар җөмләләрдә сүзләрне бәйләү өчен кулланыла. Дәрәҗә белән төрләнә алмаган сыйфатлар* ***нисби*** *сыйфатлар була. Сыйфат фигыль бер үк вакытта сыйфат һәм* ***фигыль*** *билгеләрен ала. Каршы куючы теркәгеч алдыннан* ***өтер*** *куела. Ияртүле бәйләнеш нәтиҗәсендә сүзтезмә һәм* ***җөмлә*** *барлыкка килә. Ия һәм* ***хәбәр*** *– җөмләнең баш кисәкләре.*

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(14 балл)**

Мисал өчен үрнәк бирелә, тик укучы башка сүзләр, синонимнар да файдаланган булырга мөмкин. Иң мөһиме: җөмлә төзелешенә, стиль, фактик һ.б. хаталарга игътибар итәргә кирәк.

*Малай матур һәм акыллы әкиятләр укырга яраткан һәм анда язылганнарга ышанган. Шуңа күрә ул тормыштан да могҗизалар эзләгән, ләкин яраткан әкияттәгеләренә охшаган берничә дә күренешне таба алмаган. Үзенең эзләнүләреннән берникадәр күңеле кайткач, ул әнисеннән могҗизаларга ышану дөресме икәнлеген сораган. Әллә томышта алар юкмы?*

*"Кадерлем минем, - дип, яратып эндәшкән әнисе аңа, - әгәр син яхшы күңелле малай булып үсәргә тырышсаң, бөтен әкиятләр дә синең гомереңдә тормышка ашачак. Исеңдә калдыр: могҗизаларны эзләмиләр, алар әйбәт кешеләргә үзләре килә".*

2. Сез могҗизага ышанасызмы? Малайның әнисе хаклымы? Шул хактагы фикерләрегезне 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**

*Тартык авазга тәмамланган иҗек* ***ябык*** *иҗек дип атала. Язылышлары төрле, әйтелешләре бертөрле булган сүзләр* ***омофоннар*** *дип атала. Мин, без –* ***сөйләүчеләр;*** *син, сез – тыңлаучылар.* ***Чама*** *саны предметның исәбен якынча белдерә.* ***Инфинитивның*** *юклык төре -маска/-мәскә кушымчалары ярдәмендә ясала. Кисәкчәләр сызыкча, аерым һәм* ***кушылып*** *языла ала. Эш-хәлнең, хәрәкәтнең максатын белдереп, җөмләнең фигыльне ачыклап килә торган иярчен кисәге* ***максат*** *хәле дип атала. Сорау җөмлә сорау* ***алмашлыклары*** *белән белдерелә. Иярчен җөмлә төзелеше ягыннан* ***аналитик*** *һәм* ***синтетик*** *була.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(14 балл)**

Мисал өчен үрнәк бирелә, тик укучы башка сүзләр, синонимнар да файдаланган булырга мөмкин. Иң мөһиме: җөмлә төзелешенә, стиль, фактик һ.б. хаталарга игътибар итәргә кирәк.

Ә ни өчен син?

Кечкенә Аю баласы үзенең Әтисеннән:

- Әйт әле миңа, бүре батырмы? – дип сораган.
- Ул бик кыю, миңа караганда күпкә батыррак, - дип җавап биргән аю.
- Ә юлбарыс көчлеме? – дип соравын дәвам иткән Аю баласы.
- Әйтеп бетергесез көчле, мин аның белән ярыша да алмыйм.
- Ә селәүсен җитезме?
- Ул шулкадәр җитез, ул нәрсәдер аулаганда, хәтта яфрак та селкенми.
- Төлкене бик акыллы дип әйтәләр.
- Әйе, улым, дөрес әйтәләр. Ул, чыннан да, акыллы.
- Ник алай булгач, әтием, син – урман хуҗасы, ә юлбарыс та, бүре дә яки акыллы төлке дә түгел, - дип, аптырап сораган Аю баласы.

2. Әтисе улына ни дип җавап бирде икән? Әсәрнең ахырын язып бетерегез, үз фикерегезне белдереп, нәтиҗә ясагыз, 15 җөмлә ярдәмендә бәйләнешле текст төзегез. **(15 балл)** (Бүре куркубелмәс, ләкин саклана белми. Юлбарыс көчле, ләкин бик кызып китүчән. Селәүсен җитез, ләкин бик еш кына үзенең тапкан әйберсен саклап кала алмый. Төлке акыллы, ләкин башкаларны хәйләләгәндә, ул үзе капкынга эләгә. Ә мин төрле очракларда я төлке, я юлбарыс, я бүре була алам. Шуңа күрә мин – урман хуҗасы)